Абдулла Алиш
әкияте буенча

Тылсымлы Сәхифәләр

# БИКБАТЫР белән БИККУРКАК





Абдулла Алиш
*әкияте буенча*

# БИКБАТЫР белән БИККУРКАК



Татармультфильм



Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, кишер кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.



Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа бала «Бикбатыр» дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрли, шуңа ул аны «Биккуркак» дип атаган.



Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән.



Куркуыннан куян нишләргә дә белмәгән, ярдәм сорап кычкыра башлаган. Шул вакыт песи килеп җиткән.



— Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан үлгән булыр идем, — дигән куян.



— Әй юләр, юләр, үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич, — дип, Биккуркактан көлгән Бикбатыр.



Бервакытны куян куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп типкән, чөнки нәрсәдер бик нык итеп кыштырдый икән. «Хәзер идән астыннан чыга да кыштырдаучы нәрсә мине кабып йота», — дип уйлый икән куян.

Песи дә колакларын торгызган. «Ул да курка, ахры», — дип уйлаган куян. Шулчак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян һушсыз була язган. Караса, песи авызына нәрсәдер капкан.






Ул куян янына килгән дә:


— Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде, — дип, бер кечкенә генә кара әйберне куянга күрсәткән.



— Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы? — дигән куян, гаҗәпләнеп.



Бервакыт ишектән эт килеп кергән дә каты итеп өрергә керешкән. Куркуыннан куян караватастына качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан һәм, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан.



Эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган ул. Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.



Ә Бикбатыр, үзенең батырлыгы аркасында, бу бәладән дә бик оста котылган.



## Художественное издание

Татар телендә Абдулла Алиш әкияте

Сказка Абдуллы Алиша на татарском языке

Руководитель проекта **Азат Ганиев**
Литературные редакторы: **Алсу Марданова, Фарида Ахметзянова, Айсылу Муртазина**
Художественный редактор **Дамир Бариев**
Художник **Гузель Гилазетдинова**
Компьютерная вёрстка **Дамира Бариева**
Главный режиссёр **Сергей Киатров**
Технический директор **Марат Башаров**
Анимация: **художники-мультипликаторы объединения «Татармультфильм»**

Печать офсетная, тираж 6000 экз.
Заказ № 20171
Отпечатано с готового оригинал-макета
издательства «Татармультфильм»
в типографии ООО ПО «Промполиграф».

© Объединение «Татармультфильм»